# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклау торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**14.11.2025** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклау авылында 2026 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 31 октябрендәге 4 номерлы карары нигезендә 2025 елның 14 ноябрендәге 13.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклау авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә Өчиле Саклау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш гражданнардан 2026 елда үзара салым акчаларын кертергә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итергә алынган акчаларны җибәрергә:

1) Өчиле Саклау торак пункты чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү гидранты кую)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, вак таш җәю, юлларны кардан чистарту, үлән чабу);

2. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина